**Тәһарәт**

# Белмәү гаеп түгел. Әмма белмәгән нәрсәләребезне белергә тырышмау гаеп

Белмәгән нәрсәләребезне өйрәнү тәсбих тартудан, нәфел намазлары укудан, Коръән укудан да саваплырак (әҗерлерәк). Бүген бәгъзе бер адәмнәрнең сорауларына таянып, Ислам диненең иманнан кала иң әһәмиятле фарызларыннан пакьлек, тәһарәт хакында кыскача гына исегезгә төшерәм.

Тәһарәт ике төрле: тәһарәт кубра, тәһарәт сугъра.

Тәһарәт лөгатьтә ягъни телдә: нәзафәт, пакьлек, чисталык мәгънәсендә килә. Шәригатебездә, әгәр тиешле булса, бөтен тәнебезне пакьләү (госел коену) олуг (тәһарәт) санала.

Икенчесе - намаз укыр өчен алына торган тәһарәт кече пакьлек була.

Боларның фарызлыгына Коръәндә «Маидә» сүрәсендә 6 нчы аятендә әйтелә:

**«Ий мөэминнәр! Әгәр намазга басарга теләсәгез, башта тәһарәт алыгыз...».**

Бу аятьләр белән безгә арусызлыктан пакьләү фарыз була.

Арусыз, тәһарәтсез рәвештә намаз уку һич дөрес түгел.

Мөселман булган адәмнең тәне,
киеме,
урыны,
йорты,
җире,
урамнары,
гомумән, бөтен нәрсәләре пакь, чиста булырга тиеш.

Бу хакта Пәйгамбәребез хәдисшәрифләрендә бәян кыла.

Ислам диненең пакьлеккә шушы дәрәҗәдә әһәмият бирүенә хәйран калырлык (Ислам дине мең ярым ел элек пакьлекне безгә бурыч итеп куйган). Вәхәләнки хәзерге 20 нче гасыр табиблары медицина галимнәре пакьлекне инсаният галәменә иң кирәкле әһәмиятле кагыйдәләрдән итеп китереп куялар.

**Тәһарәт кубра (госел)** бөтен тәнне юып коену, дигән сүз.

Госел кылачак кеше әүвәл истинҗа, гаурәтләрен пакьләр.

Беләзекләренә кадәр ике кулын юар.

Намаз тәһарәте кебек тәһарәт алыр.
Әүвәл башына,
уң иңбашына,
сул тарафына су коеп, бөтен тәненә су тидерер.

Бөтен тәнен ышкып чыгар, шушы өч мәртәбә тәненә су йөгертеп, иң соңыннан аягын юар.

Шушы рәвешле госел коенган адәм камил тәһарәтле булып, намаз укыр өчен яңадан тәһарәт алу тиеш түгел.

### Госелнең фарызлары өч:

авыз эчләрен юмак,
борын эчләрен юмак, борынга су алу,
бөтен тәненә су ирештермәк.

Чәч, каш, сакал, мыек һәм башка урындагы төкләргә, күз төпләренә, кендек эчләренә һәм йөзек, балдак, беләзек кебек нәрсәләренең һәркайсының астына су тидерү тиешле була.

Әгәр госел коенганда яки тәһарәт алганда тәнендә бер җәрәхәте булып, су тидерү зарар итәрлек булса, бу җәрәхәтләрнең өстенә ябылган кәгазь яки чүпрәк башка нәрсә булса, шушы ябылган нәрсәгә өстенә мәсех кылу белән госел һәм тәһарәт дөрес була.

### Госелнең сөннәтләре

Әүвәл нәҗес тигән урын булса аны юу.
Ике кулны юу.
Госелдән әүвәл тәһарәт алу.
Су койганда уң тарафтан башлау. Бер кат су койганнан соң, бөтен тәнне яхшылап ышкып чыгу.

Тәнендә һәр җиренә өчәр кат су ирештерү.

Госел коенганда кыйблага аркаң рәвештә булу.

Госелнең фарызларыннан берсе калса, авызга, борынга су алмасак, бөтен тәнебезгә су ирештермәсәк, госелебез дөрес булмый.

Инде госелнең сөннәтләрен тәмам ригая кылып үтәсәк, нур өстенә нур булып, камил җиренә җиткән чын пакьлек, арулык булачак.

### Госелне фарыз кыла торган сәбәпләр:

Хатын-кызларның гадәти күремнәре, бала тапканның, аруланганның соңында.

**Җөнеб булу үзе 3 төрле була**

Нәсел әгъзаларыннан кызу-дәртләнү белән нәсел суы килү.
Ир белән хатынның кушылуы.
Йокыда төшләнү.

Госел тиешле булган кешенең бөтен тәне арусыз дип хисаплана, менә шушы рәвешле җөнеб кешегә Коръән уку, Коръән тоту, мәчеткә керү, бит, кулларын юмый ашау-эчү дә мәкруһ була. Шуның өчен мөмкин кадәр тизрәк арулану, пакьләнү фарыз була.

**Һәртөрле догалар уку, сәлам бирү, тәсбих әйтү госелсез (арусыз адәмгә) дә дөрес.**

***Габделхәбир хәзрәт.***

**Намаз вакытлары** — Хиҗри буенча 1434 ел — **Апрель ае тәкъвиме** — Милади буенча 2013 ел — **Время намазов**

| Көннәр саны | | Хиҗри буенча | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Зәвәл | Өйлә | Икенде | Ахшам | Көн озынлыгы | Ястү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | дүшәмбе | 20 Җөмәдел | 4:44 | 6:14 | 12:44 | 13:05 | 17:09 | 19:17 | *13:03* | 20:47 |
| 2 | сишәмбе | 21 әл-әүвәл | 4:41 | 6:11 | 12:43 | 13:05 | 17:11 | 19:19 | *13:08* | 20:49 |
| 3 | чәршәмбе | 22 | 4:39 | 6:09 | 12:43 | 13:05 | 17:12 | 19:20 | *13:11* | 20:50 |
| 4 | пәнҗешәмбе | 23 | 4:37 | 6:07 | 12:43 | 13:05 | 17:13 | 19:22 | *13:15* | 20:52 |
| 5 | җомга | 24 | 4:34 | 6:04 | 12:42 | 13:05 | 17:14 | 19:24 | *13:20* | 20:54 |
| 6 | шимбә | 25 | 4:32 | 6:02 | 12:42 | 13:05 | 17:16 | 19:26 | *13:24* | 20:56 |
| 7 | якшәмбе | 26 | 4:29 | 5:59 | 12:42 | 13:05 | 17:17 | 19:28 | *13:29* | 20:58 |
| 8 | дүшәмбе | 27 | 4:27 | 5:57 | 12:42 | 13:05 | 17:18 | 19:29 | *13:32* | 20:59 |
| 9 | сишәмбе | 28 | 4:25 | 5:55 | 12:42 | 13:05 | 17:20 | 19:31 | *13:36* | 21:01 |
| 10 | чәршәмбе | 29 | 4:22 | 5:52 | 12:41 | 13:05 | 17:21 | 19:33 | *13:41* | 21:03 |
| 11 | пәнҗешәмбе | Җөмәдел 1 | 4:20 | 5:50 | 12:41 | 13:05 | 17:22 | 19:35 | *13:45* | 21:05 |
| 12 | җомга | әл-ахир 2 | 4:18 | 5:48 | 12:41 | 13:05 | 17:23 | 19:37 | *13:49* | 21:07 |
| 13 | шимбә | 3 | 4:15 | 5:45 | 12:41 | 13:05 | 17:25 | 19:38 | *13:53* | 21:08 |
| 14 | якшәмбе | 4 | 4:13 | 5:43 | 12:40 | 13:05 | 17:26 | 19:40 | *13:57* | 21:10 |
| 15 | дүшәмбе | 5 | 4:11 | 5:41 | 12:40 | 13:05 | 17:27 | 19:42 | *14:01* | 21:12 |
| 16 | сишәмбе | 6 | 4:09 | 5:39 | 12:40 | 13:05 | 17:28 | 19:44 | *14:05* | 21:14 |
| 17 | чәршәмбе | 7 | 4:06 | 5:36 | 12:40 | 13:05 | 17:29 | 19:46 | *14:10* | 21:16 |
| 18 | пәнҗешәмбе | 8 | 4:04 | 5:34 | 12:39 | 13:05 | 17:31 | 19:47 | *14:13* | 21:17 |
| 19 | җомга | 9 | 4:02 | 5:32 | 12:39 | 13:05 | 17:32 | 19:49 | *14:17* | 21:19 |
| 20 | шимбә | 10 | 4:00 | 5:30 | 12:39 | 13:05 | 17:33 | 19:51 | *14:21* | 21:21 |
| 21 | якшәмбе | 11 | 3:57 | 5:27 | 12:39 | 13:05 | 17:34 | 19:53 | *14:26* | 21:23 |
| 22 | дүшәмбе | 12 | 3:55 | 5:25 | 12:39 | 13:05 | 17:35 | 19:55 | *14:30* | 21:25 |
| 23 | сишәмбе | 13 | 3:53 | 5:23 | 12:38 | 13:05 | 17:36 | 19:56 | *14:33* | 21:26 |
| 24 | чәршәмбе | 14 | 3:51 | 5:21 | 12:38 | 13:05 | 17:38 | 19:58 | *14:37* | 21:28 |
| 25 | пәнҗешәмбе | 15 | 3:49 | 5:19 | 12:38 | 13:05 | 17:39 | 20:00 | *14:41* | 21:30 |
| 26 | җомга | 16 | 3:46 | 5:16 | 12:38 | 13:05 | 17:40 | 20:02 | *14:46* | 21:32 |
| 27 | шимбә | 17 | 3:44 | 5:14 | 12:37 | 13:05 | 17:41 | 20:04 | *14:50* | 21:34 |
| 28 | якшәмбе | 18 | 3:42 | 5:12 | 12:37 | 13:05 | 17:42 | 20:05 | *14:53* | 21:35 |
| 29 | дүшәмбе | 19 | 3:40 | 5:10 | 12:37 | 13:05 | 17:43 | 20:07 | *14:57* | 21:37 |
| 30 | сишәмбе | 20 | 3:38 | 5:08 | 12:37 | 13:05 | 17:44 | 20:09 | *15:01* | 21:39 |
| Дни | | Хиджри | Фаджр | Восход | Зенит | Зухр | Аср | Магриб | Долгота дня | Иша |

**Гөнаһларны бетерүче сүрә**

## Һәрбер нәрсәнең кальбе бар. Ә Коръәннең кальбе - "Йәсин"

Әнәс бин Мәлик разыяллаһү ганһү Рәсүл Әкрам саллалаһу
галәйһи вәсәлләмнән җиткергән.

Пәйгамбәребез г-м әйткән: «Һәрбер нәрсәнең кальбе бар. Ә Коръәннең кальбе -"Йәсин" сүрәсе».

**«Әгәр берәр кеше «Йәсин» сүрәсен укыса, аңа Коръәнне ун мәртәбә хәтем кылганның савабы булыр».**

Имам Газали бу сүзләрне аңлатып әйткән:

«Иманның дөреслеге кабердән кубарылуга Һәм хисап эчен җыелуга ышануда. «Йәсин» сүрәсендә кабердән кубарылу да, хисап өчен җыелу да камил рәвештә исбат һәм бәян ителгән. Тәннең сихәте йөрәк белән булган шикелле, иманның сихәте бу "Йәсин" сүрәсендә искә алынган кабердән кубарылу һәм хисап өчен җыелуга инану белән булганнан, бу сүрә дә йөрәккә охшаган».

Мәгъкуль ибне Ясирдән риваять ителгән.

Аллаһының Рәсүле саллаллаһу галәйһи вәсәлләм әйткән:

**«Үлекләрегез янында «Йәсин» сүрәсе укыгыз!»**

Шулай ук Өмме Дәрдаи риваятендә:

**«Әгәр мәеткә «Йәсин» сүрәсе укылса, Аллаһы Тәгалә ул мәетнең эшен җиңел кылыр», - диелгән.**

Хәзрәти Гайшә разыяллаһу ганһүдән җиткерелгән. Рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вәсәллəм әйткән:

«Коръәндә бер сүрә бар: ул сүрә укучыга шәфәгать кылыр, тыңлаучының гөнаһысы ярлыканыр.

Ул сүрә - «Йәсин» сүрәсе. Бу сүрәнең бер исеме - «бетерүче», икенчесе - «хөкем итүче».

**Бу сүрә укучының һәрбер гөнаһысын бетергәне өчен - «бетерүче» дип, һәрбер хаҗәте үтәлгәне өчен - «хөкем итүче», дип аталган.**

Ибен Габбастан җиткерелгән: «Коръән сүрәләреннән «Йәсин» һәм «Таһа» сүрәсен укыгыз!» («Җәмәл» тәфсире).

* * *

**Әдәп**

## Аякларыгызны берсен икенчесе өстенә куймагыз

Халык алдында әдәп белән һәм үзегезгә лаек булган урыннарга утырыгыз.

Хөрмәтле вә бөек затлар
булганда, аларның урыннарына хөрмәт итеп бераз ерак утырыгыз.

Үзләре боерыр булсалар, ул вакытта яннарына утырыгыз!

Урындыкларга утырганда ятмагыз,
бер якка авышмагыз!

Аякларыгызны берсен икенчесе өстенә куймагыз,
җиргә типмәгез,
уйнамагыз!

Сөйләүче булганда, яхшы тыңлагыз!

Кеше тавышыннан өстен тавыш күтәрмәгез.

Сөйләүченең сүзен өзмәгез.

Мәҗлестә булганнарның хәрәкәтләренә кимчелек итмәгез!

Халык каршында иң мәхәббәтсез кеше - мәҗлестә үз-үзен олы күрүчедер.

Шуның өчен үз-үзегезне башкалардан олы санамагыз.

Үз дәрәҗәгезне белүдән абайламыйча тормагыз!

**Ризаэтдин ФӘХРЕТДИН.**